**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**2020 елда Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт премияләрен бирү турында**

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт премияләре комиссиясе тәкъдимнәрен карап, **карар бирәм:**

2020 елда Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт премияләрен һәм «Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт премиясе лауреаты» исемен түбәндәгеләргә бирергә:

1. Алабуга шәһәренең тарихи-мәдәни мирасы буенча хезмәтләр циклы (9 китап) өчен – Вәлиев Наил Мансур улына, филология фәннәре докторы, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе хакыйкый әгъзасы, «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт бюджет фәнни учреждениесенең «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты» аерымланган структур бүлекчәсе Кама фәнни үзәге мөдиренә.

2. Фәнара тикшеренүләр һәм Татарстан Республикасы Свияжск һәм Болгар шәһәре объектлары мисалында Россия Федерациясе дөнья тарихи-мәдәни мирасы һәйкәлләрен саклау буенча хезмәтләр циклы өчен:

Ситдыйков Айрат Габит улына, тарих фәннәре докторы, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе мөхбир-әгъзасы, «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе Халыкара мөнәсәбәтләр институтының Тарих фәннәре һәм бөтендөнья мәдәни мирасы югары мәктәбе деканы, хезмәтнең җитәкчесенә;

Вәлиев Рафаэль Миргасыйм улына, тарих фәннәре докторы, «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе Халыкара мөнәсәбәтләр институты директоры урынбасары, бөтендөнья мәдәни мирасы кафедрасы мөдиренә;

Ларионова Татьяна Петровнага, социология фәннәре кандидаты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, «Татарстан Республикасы тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне торгызу республика фонды» коммерциячел булмаган оешмасы башкарма директорына;

Нугаев Камил Әсгать улына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанслар комитеты рәисе урынбасарына;

Силкин Артем Николаевичка, Татарстан Республикасының «Свияжск утрау-шәһәре» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе директорына;

Хәйретдинов Рамил Равил улына, тарих фәннәре кандидаты, «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең Халыкара мөнәсәбәтләр институты директорына;

Хөснетдинов Адел Альберт улына, Татарстан Республикасының «Татинвестгражданпроект» баш территориаль проект-тикшеренү фәнни-җитештерү фирмасы» дәүләт унитар предприятиесе генераль директорына.

3. «Татарстан Республикасында фундаменталь, гамәли һәм социаль әһәмияткә ия ысуллар нигезендә авыруларны һәм инвалидларны комплекслы медицина тернәкләндерүе алымнарын эшләү һәм гамәлгә кертү» хезмәте өчен:

Бодрова Резедә Әхмәт кызына, медицина фәннәре докторы, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Россия өзлексез һөнәри белем бирү медицина академиясе» федераль дәүләт бюджет өстәмә һөнәри белем бирү мәгариф учреждениесе филиалы – Казан дәүләт медицина академиясенең реабилитология һәм спорт медицинасы кафедрасы мөдире, хезмәтнең җитәкчесенә;

Әүхәдиев Эрик Ильяс улына, медицина фәннәре докторы, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Россия өзлексез һөнәри белем бирү медицина академиясе» федераль дәүләт бюджет өстәмә һөнәри белем бирү мәгариф учреждениесе филиалы – Казан дәүләт медицина академиясенең реабилитология һәм спорт медицинасы кафедрасы профессорына;

Әхмәтова Гүзәл Марс кызына, медицина фәннәре кандидаты, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Россия өзлексез һөнәри белем бирү медицина академиясе» федераль дәүләт бюджет өстәмә һөнәри белем бирү мәгариф учреждениесе филиалы – Казан дәүләт медицина академиясе директорының фән һәм үсеш буенча урынбасары, неврология кафедрасы доцентына;

Садыйков Илдар Фәнис улына, Казан шәһәренең «7 номерлы шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең 3 номерлы поликлиникасы амбулатор медицина тернәкләндерүе бүлекчәсе мөдире, табиб травматолог-ортопедына;

Хәсәнов Рөстәм Шамил улына, медицина фәннәре докторы, Россия фәннәр академиясе мөхбир-әгъзасы, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Россия өзлексез һөнәри белем бирү медицина академиясе» федераль дәүләт бюджет өстәмә һөнәри белем бирү мәгариф учреждениесе филиалы – Казан дәүләт медицина академиясе директоры, онкология, радиология һәм паллиатив медицина кафедрасы мөдиренә;

Хөсәенова Эльмира Рөстәм кызына, медицина фәннәре кандидаты, Казан шәһәренең «7 номерлы шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең үзәк нерв системасы функцияләре зарарланган авыруларны медицина тернәкләндерүе бүлекчәсе мөдиренә;

Йосыпова Наилә Зөфәр кызына, медицина фәннәре докторы, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Россия өзлексез һөнәри белем бирү медицина академиясе» федераль дәүләт бюджет өстәмә һөнәри белем бирү мәгариф учреждениесе филиалы – Казан дәүләт медицина академиясе директорының уку-укыту эше буенча урынбасары, гомуми гигиена кафедрасы мөдиренә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2020 ел, 10 декабрь
№ ПУ-832